Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз беренче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 апрель, 2023 ел № 218

Россия Эчке эшләр министрлыгының Питрәч районы буенча бүлегенең 2022 елдагы оператив-хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләре турында

«Полиция турында» 2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Питрәч районы буенча бүлегенең 2022 елдагы оператив-хезмәт эшчәнлеге йомгаклары турындагы мәгълүматны тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Россия Эчке эшләр министрлыгы Питрәч районы буенча бүлегенең 2022 елда оператив-хезмәт эшчәнлеге йомгаклары турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Россия Эчке эшләр министрлыгы Питрәч районы буенча бүлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Россия Эчке эшләр министрлыгы Питрәч районы буенча бүлек эшчәнлегенең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү буенча гражданнарның гомерен, сәламәтлеген, хокукларын һәм ирекләрен яклауга, җинаятьчелеккә каршы көрәшкә, җәмәгать тәртибен саклауга, милеккә һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшне активлаштырырга;

2.2. Террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту чараларын үтәү буенча барлык кирәкле чараларны күрергә;

2.3. Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты белән берлектә түбәндәге чаралар комплексын эшләргә:

- район юлларында аварияләрне киметү;
- көнкүреш җирлегендә кылына торган авыр җинаятьләрне булдырмау;
- олылар ягыннан балигъ булмаганнарга криминаль йогынты дәрәҗәсен киметү;
- балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау максатларында эш белән тәэмин ителешен яхшырту.

2.4. Җирле үзидарә органнары, хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый оешмалар белән берлектә җәмәгать тәртибен саклауда һәм профилактик чаралар үткәрүдә катнашу буенча максатчан эшне дәвам итәргә.

3. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов